**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге составына керүче Яңа Шөгер торак пунктында

15 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер торак пункты гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Яңа Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлар, җирлектә 18 яше тулган халыкның 30 процентынна узмаган ялгыз пенсионерлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләргә:

2. Алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:
   1) җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту:
   - Яңа Шөгер авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү),
   2) Яңа Шөгер авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү:
   - лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү;
   3) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:
   -Яңа Шөгер авылында җирләү урыны өчен чүп-чар контейнеры сатып алу;
   4) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:
   - МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова